**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2024 № 742

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Мәгариф идарәсе» МКУ составындагы муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмат-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»» 2022 елның 6 апрелендәге, 530 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» (2024елның 11 сентябрендәге 546 номерлы карар редакциясендә)

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик ярдәм күрсәтү максатларында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы икенче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль берәмлекләр составындагы «Мәгариф идарәсе» МКУ педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмат-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»2022 елның 6 апрелендәге 530 номерлы карарына (2024 елның 11 сентябрендәге 546 номерлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегенең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф бүлекләре (идарәләре) структурасындагы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең нигез окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айга төп оклад күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка “бакалавр”, “магистр” яисә “дипломлы белгеч” бирү белән расланган югары һөнәри белем бирү |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 20246,0 |
| | | | | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 20251,0 |
| | | | | |
| | | | | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлек мөдире (җитәкчесе) урынбасары: муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек;<br>Структур бүлек мөдире (башлыгы) : муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек; | - | - | 20329,0<br><br>20405,0 |

1.2. 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы «Нигезләмәгә» кушымтасының 1 пунктындагы «стимуллаштыру характерында түләүләр бирелә торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Советлар Социалистик Республикалары Союзының, Россия Советлар Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 1.12 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1.12. | “Яшьлек һәм һөнәри осталык” күкрәк билгесе; |

2. Әлеге боерык 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) Е.В. Сороковнинага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Баржанов